**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**01.11.2018** **№ 2353**

**Муниципаль мөлкәтне арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән Муниципаль мөлкәтне арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесенә муниципаль хезмәт күрсәтүне расланган административ регламент нигезендә башкарырга.

3. Үз көчен югалткан дип танырга: Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 31 маендагы 1468 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарының 1.27 пунктны. Муниципаль мөлкәтне арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (28 нче кушымта).

4. Әлеге карар Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылырга һәм халыкка җиткерелергә тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль

районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы МКУ рәисенә йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Кушымта
«Расланды»
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 01 ноябрендәге 2353 номерлы карары белән

**Муниципаль мөлкәтне арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент муниципаль мөлкәтне арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба - муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәтне алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче, мөрәҗәгать итүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы – «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ (алга таба – Палата).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: Биектау т/юл ст. Пос., Кооператив ур., 5 йорт.

Эш графигы:

Дүшәмбе-җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

шимбә, якшәмбе - ял көннәре.

Төшке аш: 12.00 дән 13.00 гә кадәр.

Белешмә өчен телефон: 8 (84365) 2-30-64, 8(84365) 2-30-86.

Керү ирекле.

1.3.2. Палатаның урнашкан урыны: Биектау авылы, Полк ур., 9 йорт.

Палатаның эш графигы:

дүшәмбе, сишәмбе, пәнҗешәмбе – 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

чәршәмбе, җомга – кабул итү көннәре түгел;

шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

төшке аш: 12.00 дән 13.00 гә кадәр.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмә өчен телефон:

Башкарма комитет: 8(84365)2-30-64; Палата: 8(84365) 3-28-54.

Керү шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайты адресы (алга таба – «Интернет» челтәре): (http://vysokayagora.tatar.ru).

1.3.4. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Башкарма комитет (Палата) биналарында урнашкан гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмати стендларда урнаштырылучы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пукнтларында (пунктчаларында) булган муниципаль хезмәте турында мәгълүматны үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша муниципаль районның рәсми сайтында (http://vysokaya-gora.tatar.ru);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

5) Россия Федерациясенең рәсми сайтында торглар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен torgi.gov.ru;

6) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында uslugi.tatarstan.ru;

7) Палатада:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон буенча;

язма (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон почта аша.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Палата белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Палатаның биналарында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, 30.11.1994 51-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.) (алга таба – РФ ГК);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар Җыелмасы, 2003, №40, 3822 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары Җыелмасы, 2010, № 31, 4179 ст.);

"Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 11 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.11.1995, N 48, 4563 ст.) (алга таба - 181-ФЗ номерлы Федераль закон);

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №155-156, 03.08.2004);

Биектау муниципаль районы Советының 2015 елның 21 сентябрендәге 7 номерлы карары белән расланган, Биектау муниципаль районы Советының 28.09.2016 № 86, 29.11.2016 N110, 26.05.2017 N145, 28.03.2018 N205 карарлары белән

кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы» (алга таба – Устав);

Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 16 февралендәге 122 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ турында нигезләмә (алга таба - БК турындагы нигезләмә)

Советның 2016 елның 8 июлендәге 64 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУсе турында Нигезләмә (алга таба – Палата турында Нигезләмә);

Палата рәисенең 2011 елның 17 январендәге 1 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерактагы урнашкан эш урыны – муниципаль районның авыл җирлекләрендә гариза бирүчеләрнең документларын кабул итү һәм бирү, консультацияләр бирү тәрәзәсе;

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) документтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуның ише хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) астында муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату аңлашыла (27.07.2010 ел, №210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст.2 п.). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 нче кушымта).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт исеме | Муниципаль мөлкәтне арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү | РФ ГК |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә органының башкарма-боеру органы исеме | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | Палата турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Аренда шартнамәсен өзү турында килешү (алга таба - өзү турында килешү);<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ ГК |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору вакыты | Гаризаны теркәгәннән соң 10[1] көннән артык түгел.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан өзү турында килешүне имзалауга киткән вакыт муниципаль хезмәт күрсәтү срогына керми (әлеге регламентның 3.5.6 пункты нигезендә).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле | 1. Юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта, җитәкче тарафыннан имзаланган, изик зат мөрәҗәгать иткән очракта, физик зат имзалаган гариза (4 нче кушымта). | |

[1]Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы суммар сроктан чыгып, административ процедураларны башкару өчен кирәкле минималь сроктан чыгып билгеләнде. Административ процедураларның озынлыгы эш көннәрендә исәпләнә.

| | | |
|---|---|---|
| документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 2. Юридик зат җитәкчесенең яисә вәкиленең шәхесен раслаучы документның күчермәсе (паспорт күчермәсе).<br>3. Гариза белән мөрәҗәгать итүче вәкиле (ышанычнамә, җыелыш беркетмәсеннән өземтә) мөрәҗәгать итсә, физик яисә юридик зат вәкиленең хокукларын (вәкаләтләрен) раслый торган документның күчермәсе.<br>Гариза һәм кушып бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>- шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат);<br>- почта аша.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми керүнең мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы башка оешмалар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында аренда шартнамәсен дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүмат бирелә.<br>Гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән. | |

| | | |
|---|---|---|
| шулай ук аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документларны үз карамагында тоткан дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә башка оешмалар | Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда аталган документларны таләп итү тыела. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда килештерү хезмәт күрсәтү өчен таләп ителгән һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Муниципаль хезмәтне килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Документларны тиешле булмаган зат тарафыннан тапшыру;<br>2)Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3)Гаризада һәм гаризага кушып бирелә торган документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген турыдан-туры аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди хилафлыклар булу;<br>4)Документларны тиешле органга тапшырмау | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигез каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр: | |

| | | |
|---|---|---|
| | 1) Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган, йә тәкъдим ителгән гаризаларда һәм (яисә) документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат бар;<br>2) Аренда шартнамәсенең гамәлдә булу вакыты. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Чират булган очракта муниципаль хезмәт алуга гариза бирү - 15 минуттан да артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратның максималь көтү срогы 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратуын, шул исәптән электрон формада да теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә.<br>Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә кергән сорату ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән, документларны | 181-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| бирүчеләрне көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән әлеге объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә, инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматка карата таләпләр | рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда башкарыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аларның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге күләме һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ераклаштырылган эш урыннарында, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул | Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>Палата бинасының җәмәгать транспортының һәркем файдалана алырлык зонасында урнашкан булуы;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, Биектау муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге мәгълүмати ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәтләр алуда тоткарлыкларны узарга ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар; | |

| | | |
|---|---|---|
| исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып | муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның да, мөрәҗәгать итүченең дә бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек озынлыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, КФҮ ерак эш урыннарында консультация, документларны кабул итү һәм бирү белән КФҮ белгече шөгыльләнә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан mfc.tatar.ru сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/), КФҮ дә алынырга мөмкин | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Консультацию о порядке получения муниципальной услуги в электронной форме можно получить через Интернет-приемную или через Портал государственных и муниципальных услуг Республики Татарстан.<br>В случае, если законом предусмотрена подача заявления о предоставлении муниципальной услуги в | |

| | | |
|---|---|---|
| | электронной форме заявление подается через Портал государственных и муниципальных услуг Республики Татарстан (http://uslugi. tatarstan.ru/) или Единый портал государственных и муниципальных услуг (функций) (http:// www.gosuslugi.ru/) | |

**3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны башкару үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерак урнашкан эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре**

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен тапшыру.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге блок-схемасы 2 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр күрсәтү

3.2.1. Гариза бирүче Палатага шәхсән үзе, телефон һәм (яки) электрон почта аша муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Палата белгече гариза бирүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тәкъдим ителә торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителә торган документациянең составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе, ышанычлы зат яки КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны Палатага тапшыра. Документлар читтәге эш урыны аша бирелергә мөмкин. Читтәге эш урыннары исемлеге 3 нче кушымтада китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон формада гариза Палатага электрон почта яки Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада алынган гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2. Гаризаларны кабул итүче Палата белгече түбәндәге эшләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклау;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү (ышанычнамә белән эш йөртелсә);

әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры килгән документларның булуын тикшерү;

документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документ күчермәләрен тиешенчә эшләү, документларда бозулар, өстәүләр, сызылган сүзләр, алдан кисәтелмәгән төзәтүләр булмау).

Кимчелекләр булмаган очракта, Палата белгече түбәндәге эшләрне башкара:

гаризаны кабул итү һәм махсус журналда теркәү;

гариза бирүчегә тапшырылган документларның исемлеге күчермәсен бирү, анда муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын, бирелгән номерны, документларны кабул итү датасын күрсәтү;

-гаризаны электрон документлар әйләнеше юлы белән Палата рәисенә карауга җибәрү.

Документларны кабул итүгә каршылыклар булган очракта, документларны кабул итүче Палата белгече гариза бирүчене гаризаны теркәүгә каршылыклар булуы турында кисәтә һәм, язма формада кабул итүгә каршы булуның сәбәпләрен аңлатып, документларны кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

гариза һәм документларны кабул итү вакыты - 15 минут;

гаризаны теркәү гариза тапшыру моментыннан бер көн эчендә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Палата рәисе (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат) гаризаны карый, башкару өчен профильле белгечне билгеләү максатларында аның эчтәлеген өйрәнә, алга таба гамәлләр буенча тәкъдимнәр бирә һәм әлеге гаризаны электрон документ әйләнеше ярдәмендә Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән вакыттан бер көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Палата белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә аренда шартнамәсен дәүләт теркәве булу турындагы сорату җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар башкаручыга гариза кергән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән соратулар.

3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр белгечләре соратып алына торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәрнамәләр (алга таба - баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар ведомствоара сорату кергән көннән алып биш көн эчендә, ведомствоара соратуга җавапны әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса, документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яисә оешмага кергән көннән алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палатага җибәрелгән документлар (белешмәләр) яисә баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү, килешүне әзерләү һәм тапшыру.

3.5.1. Электрон документлар әйләнеше ярдәмендә үтәүгә гариза кергәч, Палата белгече:

- урынга чыгып, объектны аның техник халәтен билгеләү һәм анда мебель, җиһазлар булмау (булу) предметына тикшерү үткәрә;

- арендатордан бүлмәнең ачкычларын кабул итеп ала;

- объектның фотоматериаллар һәм урынны тикшерү акты кушымтасы белән хат әзерли һәм аларны Палата рәисенә электрон документ әйләнеше ярдәмендә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура контроль бүлеге белгеченә гариза кергән вакыттан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бинаның ачкычларын арендатордан кабул итеп алу, Палата рәисенә җибәрелгән мәгълүмат һәм бинаны тикшерү акты.

3.5.2. Үтәү өчен гариза кергәч, Палата белгече

- әлеге регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуны тикшерә;

- баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, аренда шартнамәсен өзү турында хәбәр итү проектын (алга таба - хәбәрнамә) һәм аңа теркәлә торган аренда шартнамәсен өзү турында килешү имзалау кирәклеген (алга таба - өзү турында килешү) әзерли. Өзү турындагы килешүгә аерылмый торган кушымта булып кабул итү-тапшыру акты тора.

- баш тарту өчен нигезләр булган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарткан хат проектын (алга таба - баш тарткан хат) әзерли.

Арендаторның аренда түләве буенча бурычы булган очракта, хәбәрнамәдә шулай ук, бурыч суммасын һәм банк реквизитларын күрсәтеп, аны каплау турында таләп була.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: әзер хәбәрнамә проекты

3.5.3. Палата белгече:

- Палата рәисе белән хәбәрнамә (баш тарту белән хат) проектын килештерә;

- электрон документлар әйләнеше юлы белән Башкарма комитет җитәкчесенә (ул вәкаләт биргән затка) имза кую өчен кәгазь чыганакта хәбәрнамә проектын (баш тарту хатын) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң

бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә (ул вәкаләт биргән затка) имза салуга юнәлдерелгән хәбәрнамә (баш тарту хаты).

3.5.4. Палата рәисе (ул вәкаләт биргән зат) кабул ителгән карарның дөреслеген бәяли, хатның эчтәлеген һәм рәсмиләштерүне килештерә, аңа электрон документ әйләнеше системасында, шулай ук кәгазь чыганакта кул куя. Секретарь аша хат Башкарма комитетның гомуми бүлегенә тапшырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган хәбәрнамә (баш тарту хаты).

3.5.5. Башкарма комитетның гомуми бүлеге белгече хәбәрнамәне (баш тарту хатын) электрон документлар әйләнеше системасында, шулай ук кәгазь чыганакта терки һәм мөрәҗәгать итүче адресына почта аша җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура 15 минут дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) хәбәрнамә (баш тарту хаты).

3.5.6. Мөрәҗәгать итүче, хәбәрнамә алганнан соң, аренда бүлегенә өч нөсхәдә кабул итү-тапшыру акты белән өзү турында имзаланган килешүне тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: аренда бүлегенә мөрәҗәгать итүче тарафыннан кул куелган һәм тапшырылган кабул итү-тапшыру акты белән өзү турында килешү.

3.5.7. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан кабул итү-тапшыру акты белән өзү турында имзаланган килешүне тапшырганнан соң, Палата белгече аны кәгазь чыганакта Палата рәисенә (ул вәкаләт биргән затка) имза салуга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче тарафыннан өзү турында килешү тапшырылган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Палата рәисенә (ул вәкаләт биргән затка) җибәрелгән кабул итү-тапшыру акты белән өзү турында килешү.

3.5.8. Палата рәисе (ул вәкаләт биргән зат) кабул итү-тапшыру акты белән килешү эчтәлеген тикшерә, аңа кул куя һәм кәгазь чыганакта Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Палата белгеченә җибәрелгән кабул итү-тапшыру акты белән өзү турында имзаланган килешү.

3.5.9. Палата белгече:

- теркәү журналында өзү турындагы килешүне терки;
- гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) өзү турында килешү бирелү датасы һәм вакыты турында хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар Палата рәисе (ул вәкаләт биргән зат) тарафыннан өзү турында килешү имзаланган көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: өзелү турында теркәлгән килешү һәм өзү турында килешү бирелү датасы һәм вакыты турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.10. Аренда бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә өзү турында килешүне имза куйдырып бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура 15 минут дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән өзү турында килешү.

3.6. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.6.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтелү турында КФҮкә, КФҮнең еракта урнашкан эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.6.2. КФҮ аша гаризаларны кабул итү билгеләнгән тәртиптә расланган КФҮ эше регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.3. КФҮдән муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кергәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3 – 3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе КФҮкә җибәрелә.

3.7. Техник хаталар төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хаталар ачыкланган очракта, гариза бирүче Палатага тапшыра:

- техник хаталарны төзәтү турында гариза (4 нче кушымта);

- гариза бирүчегә техник хата булган муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

юридик көчкә ия, техник хаталар булуын таныклаучы документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларда күрсәтелгән белешмәләрдә техник хаталарны төзәтү турында сорап язылган гаризаны гариза бирүче тарафыннанм (вәкаләтле вәкил) шәхсән үзе, яки почта аша (шул исәптән электрон почтаны кулланып), дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең Бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәге аша тапшыра ала.

3.7.2. Документларны кабул итү буенча җаваплы белгеч техник хатаны төзәтүне сорап язылган гаризаны кабул итә, бирелгән документлар белән бергә терки һәм Палатага тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гаризаны теркәгән вакыттан бер көн эчендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Комитет белгеченә каралуга җибәрелгән гариза.

3.7.3. Палата белгече документларны тикшерә, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максаты белән гамәлдәге Регламентның 3.5 пункты белән каралган процедураларны башкара һәм төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имза куйдырып тапшыра һәм гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен ала яки гариза бирүченең адресына почта аша (электрон почта аша) Палатага техник хата булган документ нөсхәсен тапшырып, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура техник хата табылган яки кызыксыну белдергән теләсә кайсы заттан хата булу турында гариза кабул иткәннән соң өч көн эчендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

**4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм**

**формалары**

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә ала: гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының шикаятьләрен карау, үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләү керә.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документларның проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр план нигезендә (җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ярты еллык яки еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр дә карала ала, яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында Палата җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлеше эзлеклелегенә агымдагы контроль, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Палата рәисе, шулай ук Палата белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар турында нигезләмәләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту, Палата эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт

күрсәтү вакытында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөреслеккә туры килә торган мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аркылы тормышка ашырыла.

**5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлеге белән каралган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүченең судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе**

5.1. Муниципаль хезмәтне алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Палата хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр шикаять белән Палатага, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Башкарма комитет хезмәткәрләренең Башкарма комитетка, Башкарма комитеты җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) - муниципаль берәмлек Советына шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять закон белән билгеләнгән тәртиптә шикаять ителә.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән муниципаль хезмәтне күрсәтү турында соратуның теркәү срогын бозу.

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмуларына) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә билгеле дәүләт яки муниципаль хезмәтне тулы итеп, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин.

3) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерацисе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларында каралмаган документлар таләп итү;

3) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда күздә тотылган документларны яки мәгълүмат яисә гамәл таләп итү;

4) Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен аларның бирелүе каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнар, һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында кире кагу өчен җирлек булмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту.

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткән очракта Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә күздә тотылган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә документларда алар җибәргән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту, яисә андый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган очракта;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирүнең срогын һәм тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында моның өчен нигез булмаса;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр муниципаль хезмәт күрсәткән вакытта кирәкле булган документларны кире какканда, аларның юклыгы һәм (яки) тулы булмаганлыгы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматларны таләп итү, яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пунктында каралган очраклардан кала.

5.3. Муниципаль хезмәтне алучы шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алырга хокуклы.

5.4. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада җибәрелә.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, Биектау муниципаль районы рәсми сайты (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү почта, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (функцияләр), шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының “г” бүлегендә каралган оешмалар һәм шулай ук аларның хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына)

шикаять белдерү почта, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (функцияләр), шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау срогы – аны теркәгән көннән башлап, унбиш эш көне дәвамында. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының кире кагуын шикаять иткән очракта, күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тарткан яисә җибәрелгән ялгышларны һәм хәреф-хаталарын төзәтүдә яки әлеге төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган вакытта - аны теркәгән көннән башлап, биш эш көне дәвамында.

5.6. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтү органы вазыйфаи затының, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) аларның хезмәткәрләренең исемнәре;

2) гариза бирүчегә җавап бирү өчен гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта), яшәү урыны турында белешмә яисә гариза бирүче - юридик затның исеме, урнашкан урыны турында белешмә, хәбәрләшү өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслары) (ахыргысы булган очракта) һәм почта адресы;

3) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче муниципаль хезмәт күрсәтү органы, муниципаль хезмәт күрсәтү органы вазыйфаи заты, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләре турында мәгълүматлар;

4) муниципаль хезмәте күрсәтү органы, муниципаль хезмәте күрсәтү органы вазыйфаи заты, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмауларына) белән гариза бирүче килешмәве нигезендә дәлилләре.

5.7. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар, яисә аларның күчермәләрен тәкъдим ителә ала (булган очракта).

5.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу формасында, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән гаризаны кертү вакытында җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү буенча төзәтмәләрне, гариза бирүчегә акчалата чараларны кире кайтару, әгәр акча алу Россия Федерациясе

норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә каралмаган булса;

2) шикаять канәгатьләндерелүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгәннең икенче көннән үк соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә, теләге булган очракта электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре күрсәтелгән дәлилләнгән җавап хаты җибәрелә.

5.8.1. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә җибәрелә торган җавапта дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында ачыкланган кагыйдә бозулар кичекмәстән юкка чыгару өчен муниципаль хезмәт күрсәтү органының, күпфункцияле үзәкнең, яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмаларның эшчәнлекләре турында мәгълүмат бирелә, шулай ук гариза бирүчедән китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм киләчәктә муниципаль хезмәт алу максатларында гариза бирүче эшләргә тиешле эшчәнлек турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8.2. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләрен аңлатып нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Карарны кабул итү барышында яки шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу билгеләре тарафыннан хокук бозу очраклары ачыкланса, шикаятьятләрне карау буенча вәкаләтләргә ия булган вазыйфаи зат яки хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

1 нче кушымта

кемгә ________________________________________
(муниципаль берәмлекнең җирле
________________________________________
үзидарә органы исеме)
кемнән
________________________________________
______________________ (алга таба – гариза бирүче).
(юридик затлар өчен - тулы исеме, оештыру-хокукый формасы, дәүләт теркәве турында белешмәләр; физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны буенча теркәлүе, телефон)

Муниципаль мөлкәтне арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү турында
ГАРИЗА

Сездән _________________ белән бәйле рәвештә, муниципаль мөлкәтне арендалауның ____________________________ _________ ур.(пр.) _______ й. адресы буенча урнашкан ____________ кв. м мәйданлы ___________ _________ номерлы гамәлдәге шартнамәсен өзүегезне сорыйм.
Юридик затлар өчен: ОГРН _____________________
ИНН _____________________

Гаризага түбәндәге ялган документлар теркәлә:
1) Юридик зат вәкиленең шәхесен таныклый торган документлар күчермәсе (паспорт күчермәсе).
2) юридик затның гамәлгә кую документлары (устав, гамәлгә кую шартнамәсе).
3) Әгәр гариза белән мөрәҗәгать итүче вәкиле (ышанычнамә, җыелыш беркетмәсеннән өземтә) мөрәҗәгать итсә, физик яисә юридик зат вәкиленең хокукларын (вәкаләтләрен) раслый торган документ күчермәсе.
4) Муниципаль мөлкәтне арендалауның гамәлдәге шартнамәсе күчермәсе.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, блокадалау, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле бүтән гамәлләр кабул итүне дә кертеп) үз ризалыгымны, мине вәкилләгән затның ризалыгын раслыйм, шул исәптән автоматлаштыру режимында, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп.

Раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мине вәкилләгән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес.

Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм анда дөрес мәгълүматлар кертелгән.


Телефон аша бирелгән муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга үземнең ризалыгымны бирәм: ________________________.

_______________ ___________________ ( ___________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.)

2 нче кушымта

# Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлләренең эзлеклелеге блок-схемасы



3 нче кушымта

Читтәге эш урыннарының исемлеге һәм документларны кабул итү графигы

| № т/б | Читтәге эш урынының урнашу урыны | Хезмәт күрсәтелә торган торак пунктлар | Документларны кабул итү графигы |
|---|---|---|---|
| 1 | ТР, Биектау районы, Биектау ав., Полк ур., 9 йорт | Биектау районы торак пунктлары | Эш графигы:<br>дүшәмбе, җомга – 8.00 дән 17.00 гә кадәр;<br>шимбә, якшәмбе – ял көннәре;<br>көндезге аш 12.00 дән 13.00 гә кадәр. |

4 нче кушымта

Татарстан Республикасы
______________муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә
кемнән______________________

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтү исеме)

Язылган:_________________________________________________________
________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:______________________________________________
________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон документны җибәрү адресы E-mail:_______;

расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша түбәндәге адрес буенча: ______________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, блокадалау, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле бүтән гамәлләр кабул итүне дә кертеп) үз ризалыгымны, мине вәкилләгән затның ризалыгын раслыйм, шул исәптән автоматлаштыру режимында, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп.

Раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мине вәкилләгән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес.

Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм анда дөрес мәгълүматлар кертелгән.

Телефон аша бирелгән муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга үземнең ризалыгымны бирәм: ________________________.

________________ ___________________ ( __________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.)

Кушымта
(белешмә)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Биектау муниципаль районы Палатасы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Палата рәисе | 3-28-53 | pizobiektau@mail.ru |
| Палата белгече | 3-28-54 | pizobiektau@mail.ru |

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 2-30-61 | biektau@tatar.ru |
| Башкарма комитет эшләр идарәчесе | 2-30-63 | biektau@tatar.ru |